Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
СОВЕТЫ

# КАРАР

2015 елның 16 июле № 51/2

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль хокукый актларны гамәлдәге федераль законнарга туры китерү максатларында, прокурорның 2015 елның 22 июнендәге 02-01-02 номерлы протестын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 29 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә Чүпрәле районы прокуроры протестын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2008 елның 23 сентябрендәге 34/3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (2008 елның 30 декабрендәге 38/5 номерлы, 21.04.2009 елдагы 41/4 номерлы, 04.03.2010 елдагы 48/5 номерлы, 09.02.2013 елдагы 27/2 номерлы, 2014 елның 9 апрелендәге 40/2 номерлы редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1) 3 нче бүлектә:**
**а) 3.1 өлешендәге 3.1.1 пунктының 7 пунктчасында** «квалификация күтәрү» сүзләрен «өстәмә һөнәри белем алу» сүзләренә алмаштырырга;»;

**б) 3.2 өлешнең 3.2.3 пунктында:**
**1 пунктча** үз көчен югалтты;
**3 нче пунктчаны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«3) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, шулай ук хуҗалык итүче субъект белән идарә итүдә катнашырга (торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларыннан, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларыннан, күчемсез милек милекчеләре ширкәтеннән һәм билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һөнәр

берлекләреннән тыш), әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса яисә федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль хокукый актта билгеләнгән тәртиптә аңа әлеге оешма белән идарә итүдә катнашу йөкләнмәгән булса;»;

**2) 5 нче бүлектә:**

**а) 5.3 өлешнең 5.3.4 пунктында** «өстәмә һөнәри белем алу өчен» сүзләрен «өстәмә һөнәри белем алу өчен» сүзләренә алмаштырырга;»;

**б) түбәндәге эчтәлекле 5.6 өлешен** өстәргә:

«**5.6. Муниципаль хезмәт өчен кадрларны шартнамә нигезендә әзерләү**

5.6.1. Муниципаль хезмәтнең югары квалификацияле кадрлар составын формалаштыру максатларында җирле үзидарә органнары, мәгариф турында Россия Федерациясе законнары нигезендә һәм әлеге Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, шартнамә нигезендә, гражданнарны муниципаль хезмәт өчен әзерләүне оештыра алалар.

5.6.2. Муниципаль хезмәтне алга таба узу йөкләмәсе белән максатчан уку турында шартнамә (алга таба - максатчан уку турында шартнамә) җирле үзидарә органы белән граждан арасында төзелә һәм уку тәмамланганнан соң гражданның күрсәтелгән җирле үзидарә органында билгеләнгән вакыт дәвамында муниципаль хезмәт узу буенча йөкләмәсен күздә тота.

5.6.3. Максатчан уку турында шартнамә төзү конкурс нигезендә Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла. Максатчан уку турында шартнамә төзүгә конкурс үткәрү турындагы мәгълүмат муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару гамәлгә ашырыла торган басма массакүләм мәгълүмат чарасында басылып чыгарга һәм җирле үзидарә органының "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында күрсәтелгән конкурсны уздыру датасына кадәр бер айдан да соңга калмыйча урнаштырылырга тиеш.

5.6.4. Максатчан белем алу турында шартнамә төзүгә конкурста катнашу хокукына Россия Федерациясе дәүләт телен белүче һәм көндезге уку формасы буенча беренче тапкыр урта һөнәри яки югары белем алучы гражданнар ия. Күрсәтелгән конкурста катнашучы граждан муниципаль хезмәткә керү вакытына, шулай ук әлеге өлешнең 5 пунктында каралган бөтен срок дәвамында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен гамәлдәге законнар белән билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш.

5.6.5. Максатчан укуын тәмамлаганнан соң, муниципаль хезмәтне мәҗбүри үтү срогы максатчан укыту турында шартнамә белән билгеләнә. Күрсәтелгән срок дәвамында җирле үзидарә органы максатчан укыту турында шартнамә нигезендә гражданга социаль ярдәм күрсәтү чараларын биргән, әмма биш елдан да артмаган сроктан ким булмаска тиеш.

5.6.6. Максатчан укыту турында шартнамә якларының йөкләмәләре һәм җаваплылыгы Россия Федерациясе законнары нигезендә максатчан укыту турында шартнамә белән билгеләнә.

5.6.7. Максатчан укыту турында килешү граждан белән бер тапкыр төзелергә мөмкин.

5.6.8. Максатчан укыту турында килешүдә каралган чыгымнарны финанс белән тәэмин итү җирле бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.».

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чүпрәле муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе Әхмәтова Э. С. йөкләргә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Советы Рәисе: А.В. Шадриков